Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

# ТЫЛСЫМ+

Бишенче сан

Гыйнвар, 2016 нчы ел

## Бу санда:

Гимназия сулышы 1

Сулагайлык - кимчелекме? 2

Кошларга ярдәм итик 3

Буш вакытың бушка үтмәсен 4

## Грипптан сакланыгыз!

1. Режим саклау мөһим: ял итәргә, туйганчы йокларга, сыйфатлы тукланырга кирәк.
2. Рационда С витаминына бай ризыклар лимон, суган, кәбестә, яшелчә, җиләк-җимеш өстенлек итәргә тиеш.
3. Кулны сабынлап юуны, дизенфикцияләүче салфеткалар белән чистартуны, борынны су белән чайкатуны, бүлмәләрне җилләтүне ешайтырга кирәк.
4. Грипп чорында халык күп җыела торган урыннарга, кунакка барудан, үзеңә кунак чакырудан тыелып торыгыз.
5. Профилактик прививка ясату - гриппка каршы иң кулай чара.

*Район үзәк хастаханәсенең баш табиб урынбасары Рамил Морзаханов белән әңгәмәдән*

# ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

## “Ел укытучысы - 2016” бәйгесе



**“Ел укытучысы - 2016”** һөнәри бәйгесенең муниципаль этабында гимназиянең башлангыч сыйныф укытучылары Л.Г.Мортазина, Л.Ә. Фәхертдинова, физик тәрбия укытучысы Д.Г.Шәйхетдинов, тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, гимназия директоры А.Ф.Мирзаянов катнаштылар. Һәр укытучы үзенчәлекле мастер-класслар оештырдылар, шулай ук заманча педагогик технологияләр кулланып, ачык дәресләр күрсәттеләр. Бәйге таләпләре буенча, иң югары баллар белән, Л.Ә. Фәхертдинова Гран-при иясе булды. Ул зона этабында чыгыш ясарга әзерләнә. Ләйсән Әхмәтгаяновнага уңышлар

## Технология укытучылары киңәште

Гимназия базасында «ФГОС шарталарында укытучыларның педагогик осталыгын үстерү» темасы астында технология укытучылары семинары узды. Семинарның максаты: технология укытучыларының педагогик осталыгын, профессиональ компетентлыгын үстерү. Барлыгы 21 укытучы катнашты. Гимназия укытучылары Р.Г.Ахунов 7 нче сыйныфта ачык дәрес, Л.Ф.Солтанова мастер-класс күрсәттеләр.

## Методик семинар



Мөслим гимназиясе базасында физика укытучыларының методик семинары үтте. Укытучылар Зөлфирә Саяхова үткәргән ачык дәресне һәм мастер-класс карадылар. Семинарда Түбән Табын мәктәбенең технология укытучы Фәрит Вәлиев та катнашты. Ул үзенең укучылары белән бергә эшләнгән проектлары, 3D-басма алымнары белән таныштырды. Һөнәри конкурсаларда катнашуны оештыру эшләре буенча Тат.Бүләр мәктәбе укытучысы Айдар Ялалов чыгышы тыңланды.

## Студентлар белән очрашу

Традиция буенча, гыйнвар-февраль айларында гимназия элекке елларда тәмамлаган укучыларын кабат үзенә җыя. Республикабызның төрле уку йортларында белем алучы студентлар, каникуллар җиткәч, туган гимназияләренә кунакка кайталар. Коридорда аларның укытучылар белән җылы аралашуын күрергә була. Иң кызыгы - студентлар белән очрашу кичәсе. Быел очрашуны 10 нчы сыйныф укучылары әзерләде. Залда гимназияне төрле елларда тәмамлаган укучылар бик күп иде. Бергәләшеп аралашу төрле кызыклы уеннар, кызыксындырган сорауларга җаваплар бирү белән чиратлашты. Җылы очрашу матур тәэсирләр калдырды.

## Мин - Рәсәй гражданины

«Мин - Рәсәй гражданины” социаль проектлар конкурсы нәтиҗәләре билгеле булды. Конкурсның район этабына экология, тирә-якны төзекләндерү, кече Ватаныбыз герое, социаль проблемалар буенча 8 проект тәкъдим ителде. «Онытылган чишмәләргә - яңа тормыш» проекты белән чыгыш ясап, Әһлиуллина Язилә һәм Бәдертдинова Динара «Экология» номинациясендә беренче урын яуладылар. Кызларны һәм аларның җитәкчесе Л.Ф.Бариеваны җиңүләре белән котлыйбыз!

# СУЛАГАЙЛЫК – КИМЧЕЛЕКМЕ?



Элек сулагайлык нормадан тайпылыш, җитешсезлек булып санала иде. Шуңа күрә укытучылар әти-әниләргә: "Балагызны уң кулы белән язарга өйрәтегез!" – дигән таләп куйган һәм ата-аналар ничек булдыра ала, шулай өйрәткән. Баланы бу рәвешле "норма"га китерү эзсез үтмәгән, әлбәттә. Хәтта төрле нерв авыруларына да дучар иткән. Бу "ачы" тәҗрибәнең башлануы галимнәрнең "ачышы" белән бәйле. Үткән гасырның 50 нче елларында алар яңа теория тәкъдим итә. Кешенең баш миендә функцияләр бүленгән: уң ягы – конкрет-образлы эшчәнлек өчен (мәсәлән, әйберләрне исе, төсе аша ачыклау һ.б.), ә сул ягы сөйләм, уку, язу, математик, логик, аналитик фикерләү өчен җавап бирә дип санаганнар. Шул сәбәпле, сул як баш мие өстенлекле орган дип нәтиҗә ясалган. Бу теория буенча, баш миенең уң өлеше белән сул кул, ә сул өлеше белән уң кул "идарә" итү ачыкланган. Менә шушы ачышка нигезләнеп, сулагайлыкка каршы "көрәш" ачканнар да инде.

Фәнни-техник алгарыш туктаусыз дәвам итә. Соңгы берничә дистә елда уң һәм сул кулларның хәрәкәте өчен баш миенең ике ягы да катнашуын дәлилли торган яңа фактлар ачылды. Шулай итеп, сулагайлыкның килеп чыгуын өйрәнү һәм аңлату эше "ноль"гә төште дисәк тә хата түгел. Ни өчен кеше сул яки уң кулына өстенлек бирүен галимнәр өр-яңадан өйрәнә башларга тиеш була. Бүген шунысы бәхәссез: сулагайлык бала үсешенең интеллектуаль һәм физик мөмкинлекләренә зарар салучы ниндидер бер тайпылыш, җитешсезлек булып саналмый һәм ул авыру да түгел. Шулай ук баланың сул яки уң кулын уңайлы күрүе кирелек тә түгел, аның үз теләгеннән генә дә тормый, ә ми эшчәнлегенә бәйле.

Дөресен генә әйткәндә, мәктәпләрдә сулагайлык белән "көрәш" тукталу белән үк, бу тема үзенең актуальлеген җуйды. Хәзер аңлавыбызча, аны 50 нче еллар теориясенә нигезләнеп барлыкка китергәннәр һәм "ясалма" рәвештә тотып торганнар. Чөнки сулагайларга мәктәптә сул кул белән язарга рөхсәт бирү белән гади халык әлеге проблеманы онытты. Галимнәр, әлбәттә, эзләнә. Алар өчен кешенең сул яки уң кулына өстенлек бирүенең сәбәбен белү теләге сүрелә алмый.

***Мәгълүматларны Миләүшә Абдуллина, Динә Сафиуллина туплады.***

## Саннар һәм фактлар

Дөньяда сулагайлар якынча 10-15 процент кына. Сан ягыннан азчылыкны тәшкил итсәләр дә, дөньякүләм танылган кешеләрнең 50 проценты сулагай. 13 августта Халыкара сулагайлар көне билгеләп үтелә. Ә "уң куллы"лар өчен махсус көн юк.

Сулагайлык күбрәк ирләр арасында очрый.

Кешенең сул кулы белән язуы гына сулагайлык күрсәткече түгел.

Төрле җайланмаларны сулагайлар өчен яраклаштырып чыгару эше бүген шактый киң таралган.

## Бу кызык

Тарихи шәхесләр арасыннан сулагайлар: Леонардо да Винчи, Адольф Гитлер, Махатма Ганди, Уинстон Черчилль, Рональд Рейган, Альберт Эйнштейн, Бетховен, Моцарт, Чарли Чаплин, Мэрилин Монро, Уго Чавес һ.б.

Хәзергеләрдән: Барак Обама, Владимир Путин, Билл Клинтон, Усама бен Ладен, Фидель Кастро һ.б.

**P.S.** Безнең гимназиядә дә алар бар икән.

*Гайнуллин Ислам*
*Гәрәев Идел*
*Хәбибуллина Камилә*
*Ильясов Данияр*
*Гәрдиева Ильвина*
*Насаева Регина*
*Фәхертдинова Айгөл*
*Ямалов Илнар*
*Фәхразиев Илназ*
*Нуриева Камилә*
*Мәгъсумов Айзат*
*Иванов Рафаэль*
*Садыйков Райнур*
*Лотфуллин Ильяс*
*Харисов Ильнур*
*Сәлимгәрәев Нурислам*
*Гатауллин Айдар*

*Сул кул белән язучы дусларыгыз башкалардан аерыламы? Күзәткәнегез бармы? Сулагайлык — кимчелекме, әллә, киресенчә, өстенлекме?*

# КОШЛАРГА ЯРДӘМ ИТИК

***Соңгы вакытта планетабызда глобаль җылыну турында еш сөйлиләр. Шуңа да карамастан, безнең төньякта урнашкан илебездә кышлар карлы да, салкын да була. Ач организмга җылыну өчен энергия җитми! Ә кар-боз астыннан ризык табу җиңел түгел.***



Сүзебезнең кошлар турында барганын аңлагансыздыр инде. Галим-орнитологлар әйтүенә караганда, кышын һәр 10 песнәкнең 9ы ачлыктан үлә. Күчмә кошлар җылы якка китеп беткән, ә монда калганнарына, әлбәттә, без булышырга тиеш. Алар безне сайрап кына куандырмый, яз, җәй көннәрендә бакчаларыбызны, кырларыбызны корткыч бөҗәкләрдән арындырырга да булыша бит әле. Шуңа күрә безнең климат зонасында аларны өстәмә ашату зарури. Кошлар без куйган җимлекләрдән ризык таба алса, аларның язга кадәр яшәячәкләренә өмет бар, дигән сүз.

Җимлекләрне үз кулыбыз белән теләсә нинди материалдан ясый алабыз. Сөт пакетлары, катыргы, пыяла банка, пластик шешәләрдән дә менә дигән җимлек ясарга була. Аларны чыпчык, песнәк сыман нәни кошчыклар үз итәчәк. Автомат җимлекләр тагын да уңайлырак. Муенын түбәнгә каратып урнаштырылган шешәләр һәм башка шундый конструкцияләр инде алар. Пластик шешә уемнарына агачтан



кашык сыман әйберләр ясап куела. Кошчыкка керү өчен уем иркенрәк ясала, һәм ул җимне чүпләгән саен, аның аша яңа җим өстәлә бара.

Ә нинди җим салырга? Чыпчыкка – ипи валчыклары, төрле ярмалар. Кызылтүш, миләш һәм урман чыпчыгына – кипкән миләш, аю баланы, чаган орлыгы. Купшылга – көнбагыш, солы, бодай; песнәккә –





тозланмаган туңмай, ит кисәге (анысын җепкә бәйләп элсәң дә ярый).

Шунысын да онытмагыз: кошларны ашатырга алынгансыз икән инде, бу эшне туктатмагыз. Алар бит билгеле бер урында үзләрен ышыкланып оя һәм ризык көтеп торганына ияләшә һәм ышаныч белән очып килә башлыйлар. Ярдәмегезгә ияләшкән кошлар кинәт ризыктан мәхрүм калса, һәлак булырга да мөмкин бит. Буран чыккан, юеш кар яуган һәм нык салкынайтып җибәргән чакларда, аларга карата аеруча игътибарлы булыгыз.

Гимназиянең башлангыч сыйныф укучылары быел безнең якта кышлаучы кошлар өчен территориягә бик матур җимлекләр ясап элделәр. И, рәхәтләнде соң кошкайлар! Аларны күзәтеп тору—үзе бер хозурлык!

***Фәхертдинова Л.Ә.,***
***башлангыч сыйныф укытучысы***

# ГИМНАЗИЯ ЙОЛДЫЗЛАРЫ





**Фәхертдинова Айгөл**

***Биология, рус әдәбияты фәннәреннән республика олимпиадасы призеры***

**Туган елы:** 2001

**Йолдызлык:** Игезәкләр

**Хобби:** әдәби әсәрләр уку, музыка тыңлау

**Кешеләрдә иң яратмаган сыйфат:** икейөзлелек, кирәк булганда гына синең белән дус булу, эгоистлык

**Дусларның ниндие яхшы:** мәрхәмәтле, шат күңелле, ярдәмчел

**Ничек уңышка ирешеп була:** башлангыч сыйныфтан ук ныклы белем алырга, максат куярга һәм ирешергә кирәк. Ә моның өчен системалы рәвештә укырга, үзеңдә көч таба белү сыйфаты мөһим.

**Сафиуллин Ринат**

***Физик тәрбия фәненнән республика олимпиадасы призеры***

**Туган елы:** 2000

**Йолдызлык:** Арыслан

**Төп максаты:** спортта югары нәтиҗәләргә ирешү

**Кайсы спортка өстенлек бирә:** милли көрәш, хоккей, футбол

**Кешеләрдә иң яратмаган сыйфат:** ялагайлык, сатлыкҗан

**Дусларның ниндие яхшы:** гадел һәм чиста күңелле булганы

**Яраткан ризык:** бәлеш, өчпочмак

## ИҖАДИ СӘХИФӘ

# Кайту

**(хикәя)**



Кышкы көн. Биек бинаның тәрәз төбендә чандыр буйлы, арык гәүдәле кызчык тирә-юньне күзәтеп утыра. Ябалак-ябалак кар ява. Җил кар бөртекләрен әле тәрәзә каршындагы миләшнең кызыл тәлгәшләренә, әле кызчык утырган тәрәзәгә ябыштырып куя. Кояш та ара-тирә кызчыкка күзен кыскалап ала. Назгөлгә боларның барысы да кызык тоелды, ул бөтен барлыгы белән кышкы матурлыкны күзәтте. Кинәт кенә күңелсезләнеп, моңсу карашын еракка төбәде. Мәйданчыкта шау-гөр килеп балалар уйный. Кызчыкның керсез саф күңелен көнләшү биләп алды, чем-кара күзләрдән саркып чыккан яшь тамчылары, битләрендә эз калдырып, тәрәзә төбенә коелдылар. Мәйданчыкта уйнаган балалар кебек, дөньясын онытып уйныйсы, шаярасы, көләсе килде.

Сәрвиназ палатага килеп кергәндә, Назгөл үкси-үкси елый иде.

- Балам, күз нурым, ник елыйсың? Сәрвиназ кызын кочагына алды. Назгөл, әнисенең кочагыннан чыгып, аның күзләренә төбәлде:

- Әнием, бәгърем, ник мин дә алар кебек шаяра, уйный алмыйм? Ник? Ник? – дип, кечкенә йодрыклары белән әнисенең күкрәгенә бәргәләде. Сәрвиназ, күз яшьләрен кызына күрсәтмәс өчен, тамак төбенә утырган утлы күмер кебек төерен йотып җибәрде:

- Кызым, алтыным минем, савыккач, син дә мәйданчыкта уйнаячаксың. Безгә икебезгә дә нык булырга, көч җыярга кирәк. Операциядән соң барысы да яхшы булыр. Назгөл, елавыннан туктап, әнисенә елмаеп карады:

- Әнием, операция ясагач, мин терeләм, әйеме?

- Әлбәттә, карлыгачым.

- Әнием, мин терелгәч, әтием дә кайтамы?

Сәрвиназның күзләренә яшь тыгылды. Юк, юк, ул күз яшьләренә ирек бирергә тиеш түгел. Ул Назгөлне авыр чакта көчле булырга, сынмаска, сыгыл-маска өйрәтте. Хәзер сабые янында балавыз сыгып утыру эш түгел.

Кызым, әтиең сине күктән күзәтеп тора. Аңа аннан кайтырга ярамый. Ул да синең өчен борчыла, көч бирeп тора.

Ә миңа эти янына барырга ярыймы соң?

Сәрвиназның тәне эсселе-суыклы булып китте, үзе дә сизмәстән кызын күтәреп алып, кочагына кысты:

- Юк, юк, кызым, сиңа әтиең янына барырга ярамый. Син монда, җирдә кирәк. Син минем янда калырга тиешсең, - дип, караватка яткырып, өстенә йомшак юрганын япты.

Назгөл йокыга киткәч, ул табиб бүлмәсенә юнәлде. Табиб бүлмәсе янында чират шактый иде. Ана үз уйларына чумды...

Әнвәр белән алар яратышып кавыштылар, алар шундый бәхетле иделәр. Бәхет өстенә шатлык өстәп, кызлары Назгөл туды. Бар дөньялары житеш иде. Әнвәре аны күтәреп кенә йөртте. Сәрвиназ, бәхеткә уралып, “очып” кына йөрде. Әбисе: “И, кызыкаем, бигрәкләр дә түгәрәк бәхетегез, күзләр генә тия күрмәсен инде,” - ди торган иде. Әбисе хаклы булган. Аяз көнне яшен суккан кебек, Сәрвиназның бәхете минут эчендә җимерелде. Юл сәфәреннән кайтып килгәндә, аның Әнвәре зур тизлек белән килгән йөк машинасы астында калып вафат булды. Шуннан башланды инде барсы да: ире үлеп, озак та тормады, әбисе бакыйлыкка күчте. Чираттагы тикшерелү вакытында кызында кан авыруы таптылар. Шул көннән башлап, Сәрвиназның ашы аш, йокысы йокы булмады. Хастаханәдән хастаханәгә чапты. Хастаханә аның яшәү урынына әверелде. Менә хәзер дә ул ишек төбендә табиб хөкеме көтеп утыра.

- Керегез.

Уйларыннан арынып бетмәгән Сәрвиназ сискәнеп китте. Бүлмә ишеген ачып, талгын адымнар белән табиб янына якынлашты. Йөрәге чабыш атыныкыдай ашкынды. Йөзләре агарынып калды, телләре аңкавына ябышып, сүз әйтерлек көч тапмады. Табиб:

- Исәнмесез, утырыгыз бирегә, - дип, урын тәкъдим итте.

- Сәрвиназ ханым, борчылмагыз, тынычланыгыз.

Табиб, өстәлдә торган нәфис стаканга агызып, Сәрвиназга су бирде. Сәрвиназ суны бер сулышта эчеп куйды, аңа җиңел булып китте.

- Гафу итегез, Камил Әхмәтович, көннән–көн үземне көчсез итеп хис итәм, Назгөлемә ярдәм итә алмам кебек тоела.

- Сабыр булыгыз, Сәрвиназ ханым. Сез бу кыяфәтегез белән кызыгызның өмет чаткыларын сүндерәсез. Нык булыгыз! Беләм, авыр ситуация. Кызыгызда яшәүгә өмет уятыгыз. Оптимист булыгыз! Сезгә сөенечле хәбәрем бар: донор табылды. Назгөлне операциягә әзерли башлыйбыз. Бергәләп көрәшсәк, яман чирне тамырыннан йолкып ташларбыз, иншалла!

Сәрвиназ табиб бүлмәсеннән канатланып чыкты. Палатага кергәндә, Назгөл бер ноктага карап тын гына ята иде. Иң якын кешесен күргәч, киң итеп елмайды.

Кызым, сөенче! Донор тапканнар, тиздән операция ясаячаклар. Алла боерса, син дә башка балалар кебек уйнарың, шаярырсың.

Ана белән баланың күзләрендә шатлык чаткылары биеште.

...Төштән соң Назгөлне палатага кертеп салдылар. Сәрвиназ, кызының агарынып калган тыныч йөзен күргәч, сискәнеп китте. Аның аяк астында идән шуышкандай булды. Сәрвиназ беренче тапкыр күз яшьләренә ирек бирде. Ул бертуктаусыз тавышсыз гына елады да елады.

Бер тәүлек үтте. Назгөл әле наркоздан айнымады. Бер тәүлек анага ел кебек тоелды.

Назгөл үзен ямь-яшел, чәчәкле аланда итеп хис итте. Күк йөзе зәп-зәңгәр, күзләрне камаштырырдай яктылык сибелгән. Назгөлнең өстендә әтисе алып биргән эре ак борчаклы зәңгәр күлмәге. Ул болында күбәләкләр белән куышып уйный, аңа шундый җиңел, гүя аның иңнәренә канат куелган. Шулчак агачлар арасыннан әтисе пәйда булды. Назгөл “әтие-е-ем” дип аңа таба йөгерде. Әтисе Назгөлне күтәреп күкрәгенә кочты, иркәләде, маңгаеннан үпте дә:

- Менә ничек зур үскән минем Назгөлем, кара карлыгачым минем.

- Әтием мин сине шундый сагындым. Нишләп шулай озак кайтмый тордың?

- Кызым, миңа кайтырга ярамый, мин монда торам.

- Әтием мин дә синең белән калам.

- Юк, акыллым, сине әниең зарыгып көтә, син әниеңә бик тә кирәк. Сиңа монда килергә иртә әле. Бар, кайт, кызым, тоткарланма. Сау бул, кы-зы-ы-ым.

Әтисе ерагайганнан-ерагая барып, томанга кереп юк булды.

- Китмә, әтием!

Назгөл күзләрен ачып җибәргәндә, аның газизе - әнисе янында утыра иде.

- Әнием, мин әтием янында булдым. “Кызым, сине әниең көтә”, - дип, ул мине кайтарып җибәрде. Әнием, мин сине бик, бик яратам.

Җай гына көннәр үтә торды, әкренләп Назгөл дә савыга, йөри башлады. Назгөлгә кабат тикшерү уздырдылар. Тикшерү нәтиҗәләре көтелгәннән дә яхшырак булды.

Кояш туры карый башлады, җылысын да кызганмый сипте. Яз хәбәрчеләре - кара каргалар да туган оялaрын сагынып кайттылар. Зәңгәр күкне колачлап, тургайлар җыр суза. Табигать җанланган, тирә-якка җир исе, агач исе таралган. Кардан ачылган җәяүлеләр сукмагыннан кулларына бәхет кошы тоткан ике кеше атлый: ана һәм бала.

***Илүзә Кашапова,***
***9 нчы а сыйныфы укучысы***

ТЫЛСЫМ+

Гыйнвар , 2016 нчы ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Мухаметханова Айгөл,
**Корреспондентлар:** Мәгъданова Ләйсән, Фәрхетдинова Айгөл, Кашапова Илүзә
**Дизайнер:** Галиев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат, Хәбибуллин Руслан
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym